# ПАТРИОТИЗМ В ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ
# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ПАТРИОТИЗМ

**Даутов Гумар Фильгизович, Фаррахова Лейсан Флеровна**
Елабужский институт Казанского (Приволжского) федерального университета,
г. Елабуга, Татарстан, Российская Федерация
e-mail: dautovgumar@mail.ru ; farrakhova2001@bk.ru

**Аннотация.** В данной статье анализируется роль татарской литературы в патриотическом воспитании людей. С давних времен татарские писатели и просветители отдавали должное внимание развитию и укреплению чувства патриотизма у людей, у читателей. Мы приходим к выводу, что изучение татарской литературы – неотъемлемая часть патриотического воспитания, его основа, фундамент, первоисточник. Поэтому изучение литературы на героико-патриотическую тему обязательно для людей всех возрастов, начинания со школьных лет.

**Ключевые слова:** татарская литература, творчество, патриотизм, Родина, народ, гражданин, просвещение, учение, закон, эпоха.

# PATRIOTISM IN TATAR LITERATURE

**Dautov Gumar Filgizovich, Farrakhova Leysan Flerovna**
Elabuga Institute ofthe Kazan (Volga region) Federal University, Elabuga, Tatarstan, Russia

**Abstract.** This article analyzes the role of Tatar literature in the patriotic education of people. Since ancient times, Tatar writers and educators have paid due attention to the development and strengthening of the sense of patriotism among people, among readers. We come to the conclusion that the study of Tatar literature is an integral part of patriotic education, its basis, foundation, primary source. Therefore, the study of literature on heroic and patriotic themes is mandatory for people of all ages, starting from school years.

**Key words:** Tatar literature, creativity, patriotism, Motherland, people, citizen, education, teaching, law, era.

Мәкаләне Г.Тукайның “Китмибез!” шигыреннән:

*«Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;*

*Бәйләмеш бу җиргә безне тәңребез (гыйззе вә җәл).*

*Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия!*

*Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе ру сияһ!»* -

дигән өзек белән башласак, хаклы булырбыз, чөнки Тукай иҗаты бөтен әдәбиятыбызның киләчәк үсеш юлын билгели.

Россияны уртак Ватан итеп сизү татарларда бик күптәннән килә. Тарихта “Смутное время” дип исем алган дәвердә үк татар Мининның Мәскәүне саклап калудагы хәлиткеч роле иң югары җитәкче даирәләрдә дә танылды һәм бәясен алды. 1812нче елдагы Ватан сугышында да Кутузов армиясендә татар солдатлары күп була һәм шул вакытта аларның һөҗүмгә барганда “ура”, “урап ал” дип кычкырулары рус һәм башка милләт вәкилләре тарафыннан да кабатланып, бүгенге көнгә шатлыкны белдерүче сүз рәвешендә килеп җиткән.

“Татар әдәбияты тарихы”нда Ватан сугышы герое Денис Давыдовның мондый сүзләре китерелә: «Генерал Ермолов татарлардан гаскәр төзеде. Бу гаскәр көчлелектә, кыюлыкта һәм осталыкта алардан (чик буе казакларыннан) югары, һәрхәлдә, алардан бер дә ким түгел» [2, б. 11].

«Художественная литература, как вместилище исторической памяти и как конденсатор духовного опыта народа, являлась и является великим Учителем, нравственной опорой человека, каждого поколения, каждой этнической общности» [1, с. 16] – дип яза Х.Миңнегулов.

Тукай традицияләренә нигезләнеп үскән татар әдәбиятында патриотизм, үзеңне Россия гражданины итеп сизү, ил алдында бурычларыңны тану белән бергә, шушы Ватан кешесе буларак хокукларыңны да аңлау, тарихи хәтер буларак, һәм XIX йөз ахыры-XX йөз башы, һәм татар совет әдәбиятында да чагылыш тапкан. Татарларның үзләрен Россия гражданины итеп идентификацияләве әдәбиятта аерым идея буларак формалашмый, ул язучы формалаштырган, укучыга җиткерергә теләгән шул идеяның тукымасында, гадәти, табигый элементы буларак урын алган. Мәсәлән, Р.Фәхреддиннең

1899нчы елда дөнья күргән, тулысынча мәгърифәтчелек рухындагы “Сәлимә, яки Гыйффәт” әсәренең төп фикере – татар уку-укыту системасының, билгеле бер югарылыкка ирешкән булса да, башка милләтләр мәгарифеннән бик нык калышуы һәм моның өчен әле безгә бик нык тырышырга кирәк булуы турында. Моны күрсәтер өчен әдип төп геройны үзебезнең җирлектән алып, аны үз исеменнән: «Казанда булган мәдрәсәдә ун ел гомер уздырып, укыган дәресләрем күп, белгән нәрсәләрем чиксез, күтәргән китапларым хисапсыз иде», - дип тасвирлый. Сәлимә исә – Иран мәмләкәтеннән, һәм ул бар яктан да безнең шәкерттән өстен тора. Шушы чагыштыру аркылы язучы югарыда әйтелгән төп фикерне җиткерә, ләкин повесть мондый сүзләр белән башлана: «Казан – Русия дәүләтендә олугъ бер шәһәредер. Казан вилаятенең (губернасының) мәркәзе – шушы шәһәр;» яки «Ләкин аның русча белүеннән дә миңа файда булмаячак, чөнки сөйләшерлек дәрәҗәдә русчаны мин белми идем. Русча белү бик кирәк икәнлеген мин шушы вакытта үз-үземә хөкем иттем» [4, б. 7-17].

Күргәнебезчә, вакыйгалар табигый рәвештә Россия шәһәрләренең берсе булган Казанда бара, табигый ки, яшәр өчен, төпле белем алыр өчен русча белү шарт булып тора.

XX йөз әдәбиятыннан бик күп мисаллар китерергә була: Г.Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр”ендә некрутлар (солдатка алынучылар) җыелуы, Г.Исхакыйның “Теләнче кыз” романында Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында татар сәүдәгәрләренең эшчәнлеге һәм башкалар. Ләкин, безнең карашка, узган гасырның 30нчы елларында дөнья күргән әсәрләр бу ноктадан караганда кызыклы гына материал бирәләр. XX йөз башы әдипләре, нигездә, үзләре яшәгән дәвер турында язалар, һәм алар иҗат иткәндә цензура шактый йомшак була. М.Гафуриның “Кара йөзләр” повесте, М.Галәүнең “Болганчык еллар” һәм “Мөһәҗирләр” дилогиясе катгый таләпләр куйган совет идеологиясе шартларында һәм үткәннәргә мөрәҗәгать итеп, тарихи анализ, үзләре күреп-белгәнне еллар тәҗрибәсе аша чыгып бәяләү методы белән язылганнар, һәм алар шуның белән узган дәверләрне әдәби күзаллау буларак кыйммәтле.

“Кара йөзләр” повестена әдип «Иске тормышның миллион корбаннарыннан берсе» дип аңлатма бирә. Аулакта сөйләшеп торган Закир белән Галимәне “зина кылучылар” дип яла ягып, мәдрәсәдә дәрес бирүче хәзрәт каршына алып киләләр, ягъни, җәмәгатьчелек алдына хөкемгә чыгаралар. Шәкертләргә дәрес бирүче хәлфәләр катнашында зина кылучыларга шәригать тарафыннан нинди җәза бирелергә тиешлеге бик җентекләп тикшерелгәннән соң, хәзрәт, рәислек итүче буларак, мондый нәтиҗә чыгара: «Безнең бу җирдә шәригать хөкемнәрен йөртеп тә булмый. Ләкин, бозыклыкка каршы тору өчен, мондый эшләрне җәзасыз калдырып та булмый, шәригать хөкемен йөртү – безнең бурычыбыз, моның өчен фәтва китапларында сарих дәлилләр бар», - дип нәтиҗә чыгара. Ягъни, хәзрәт, гражданлык хокуклары буенча, Россия законнарына буйсынуын һәм, шул ук вакытта, ислам динен тотучы булуын таный. Ул, Россия империясе территориясенең гражданины буларак, шәригать законнарының башкаларга карата хөкем карары буларак кулланыла алмавын яхшы аңлый һәм шуның аркылы үзен, мәхәллә халкын шушы ил подданныйлары итеп идентификацияли.

Шундый ук хәл М.Галәүнең “Болганчык еллар” романында да күзәтелә. Дөрес, монда ситуация башкачарак. Кызып китеп, приставны үтереп ташлаган крестьяннар императорга гафу сорап хат язалар. Үзләренең вакытында налог түләп, кирәк кадәрле солдат биреп баруларын, димәк, гражданлык бурычларын үтәүләрен әйткәннән соң, алар дингә, дини кешеләргә кагылмау турында килешү барлыгын әйтеп, императорга хокуклары барлыгын да ачык белдерәләр. Һәм, патшага хат белән мөрәҗәгать итүләре үзе үк инде крестьяннарның анда яклаучы күреп, үзләрен шушы илнең тулы хаклы вәкилләре итеп сизүләре турында сөйли.

Узган гасырның 30-90нчы елларында патриотизм темасы, коммунистик идеологияга буйсындырылып, илне ярату тойгысыннан бигрәк, партияга бирелгәнлек хисе буларак тәкъдим ителә, һәм ул чын хистән бигрәк, ясалма рәвештә совет хакимиятенә тугрылыгыңны раслау рәвешен ала. Әлбәттә, монда Сталин репрессияләреннән курку һәм иҗатың аша үзеңнең партияга

бирелгәнлегеңне күрсәтергә  тырышу омтылышы урын ала, иҗтимагый тормышның артык сәясиләшкән булуы да шундый бер яклылыкка китерә. Әмма инде тарихта “Хрущев җепшеклеге” дип аталган чор килеп, 60нчы елларда демократик җилләр исә башлауга, каләм әһелләре туган җир, туган як темаларына мөрәҗәгать итеп, Кече Вата аша Ватанны ярату мотивын алга чыгаралар: «Гомумән, матурлык, яктылык, яхшылык, җылылык туган җирдә генә дигән фикер чор шигъриятенең лейтмотивына әйләнә. Туган җирне мифлаштыручы С.Хәким иҗаты әйдәп бара... Җанга җылылыкны да, кайгыртуны да, чиксез бәхетне дә, иҗатка илһамны да туган җирдә генә табарга мөмкин дигән фикер шагыйрь иҗатын үтәли кисеп кисеп уза». [3, б. 16]

Гомумиләштереп шуны әйтергә мөмкин: патриотизм темасы татар әдәбиятында һәр чорда төрле формада урын алган. Вакыты белән ул артык сәясиләшкән, вакыты белән чын күңел хисе рәвешендә яшәгән, әмма гасыр башында Тукайның “Китмибез!” дип кискен игълан итүе традицияләренә тугры калып, бүген дә яшәвен дәвам итә.

**Әдәбият**


1. Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики). - Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993. - 384 с.
2. Р. Фәхретдин “Сәлимә, яки Гыйффәт” һәм “Әсма, яки Гамәл вә җәза”. – Казан, “Меддок” нәшрияты, 2007. – 150 б.
3. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. – Т. 2. – 574 б.
4. Татар әдәбияты тарихы : сигез томда / [төз. Р. Ф. Рахмани]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2014. – 6 т. : 1960-1980 еллар / [фәнни мөх.: Д. Ф. Заһидуллина, Ә. М. Закирҗанов]. – 2018. – 775 б.